**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ҖӨРИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**дуртенче чакырышның чираттан тыш утырышы**

**29 июль 2024 ел** **№135** **Иске Җөри авылы**

Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советының 2009 елның 8 сентябрендәге 8 номерлы «Иске Җөри авыл җирлегенең җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең персональ күрсәткечләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында» Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 12 декабрендәге 594-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Иске Җөри авыл җирлеге Советының 2009 елның 8 сентябрендәге 8 номерлы « Иске Җөри авыл җирлегенең җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең персональ күрсәткечләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына (12.03.2021 №5, 10.03.2022 № 50, 16.01.2023 № 84 карарлар редакциясендә),түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

күрсәтелгән карар белән расланган,Иске Җөри авыл җирлегенең җирле үзидарә органында муниципаль хезмәткәрнең персональ күрсәткечләре белән эшне оештыру һәм аның шәхси эшен алып бару турындагы нигезләмәгә:

а) 2.5 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкета;

б) 2.6 пунктта «Белешмәләр» сүзеннән соң «(анкетада булган белешмәләрдән тыш)» сүзләре белән тулыландырыга

2. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Иске Җөри авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Мараков